СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ПЕЧИЩИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

10.10.2022 | с. Печищи | № 24-123

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге торак пункты территориясендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Печищи авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә, Печищи торак пунктының бер өлешенең халык төркеме инициативасын карап

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2022 елның 22 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Печищи авылы җирлегендә урнашкан торак пунктта гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Печищи авылы җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Югары Ослан муниципаль районының Печищи авылында 1 нче май, Красный Яр урамнары буйлап бистә эчендәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын 2022 елның 22 октябрендә 1 Май урамының Печищи авылы адресы буенча 40 нчы йорт янында 10.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Печищи авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
ТР Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы Е.В. Рәхмәтуллина